| ГЛАВА<br>КУЛАНГИНСКОГО СЕЛЬСКОГО<br>ПОСЕЛЕНИЯ КАЙБИЦКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОНЫ<br>КОЛАНГЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>БАШЛЫГЫ |
|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

10 ноябрь 2023 ел пос.жд.ст.Куланга № 3

Гражданнарның үзара салым акчаларын
кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча
Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль
районының Коланңгы авыл җирлеге Түбән Коланңгы
торак пунктында гражданнар җыенын билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Коланңгы авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә КАРАР КЫЛАМ:

1. 2023 елның 21 ноябрендә 08 сәг 30 минутка Түбән Коланңгы авылы , Бакча урамы, 15 йорт адресы буенча , үзара салым алып бару мәсьләләре буенча гражданнар җыенын билгеләргә.

2.Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

"Сез 2023 елда яшәү урыны буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Коланңгы авыл җирлегенең Түбән Коланңгы торак пункты территориясендә теркәлгән һәм даими яшәүче балигъ булган һәр яшәүчедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме?"

*а) җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:*

- материаллар сатып алып, юлларны норматив хәлгә китерү;
- җирлекнең торак – пунктлары чикләрендә автомобиль юлларын карап тоту.

*б) җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру:*

- авыл җирлеге торак пунктлары территорияләрен тоту;

*в) авыл җирлеге торак пунктлары чикләрендә халыкны су белән тәэмин итүне оештыру:*

- авыл җирлеге торак пунктларында материаллар сатып алып, су күтәрү

манарасын тоту;
- авыл җирлеге торак пунктларында материаллар сатып алып суүткәргеч челтәрләрен ремонтлау;

« РИЗА» «КАРШЫ»

3. Әлеге карарны Интернет - телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru веб – адресы буенча «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» һәм Кайбыч муниципаль районы Колаңгы авыл җирлегенең http://kulanga-kaybici.tatarstan.ru веб-адресы буенча рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка таратырга.

4. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Колангы авыл жирлеге башлыгы Ф.Т.Нигматзянов